ШИМБӘ
13
МАРТ
1943 ел.
№ 58 (6780)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ВЯЗЬМА ШӘһӘРЕН АЛДЫЛАР

12 нче мартта Көнбатыш фронт гаскәрләре, генерал-полковник иптәш В. Д. СОКОЛОВСКИЙ командалыгы астында, кискен штурмнан соң ВЯЗЬМА шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

Вязьма шәһәре өчен булган сугышларда безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны КУЛГА ТӨШЕРДЕЛӘР: самолетлар—8, танклар—83, төрле калибрдагы орудиеләр—69, пулеметлар—222, автомашиналар һәм тракторлар—565, паровозлар—57, вагоннар—515, бик күп снарядлар, патроннар һәм башка хәрби милекләр. Трофейларның санын алу дәвам итә.

Дошман үтерелгән хәлдә генә дә 9.000 нән артык солдатларын һәм офицерларын югалтты.

Вязьма шәһәре өчен булган сугышларда генерал-лейтенант иптәш В. Н. ГОРДОВ һәм генерал-лейтенант иптәш В. С. ПОЛЕНОВ гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр. Полковник иптәш ПЕТЕРС һәм полковник иптәш ЯБЛОКОВ частьлары шәһәргә беренче булып керделәр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

ЮЛБАШЧЫНЫҢ КОТЛАВЫ ЯҢА УҢЫШЛАРГА РУХЛАНДЫРА

Республикабызның хезмәт ияләре гаять зур шатлыклы көннәр кичерәләр. Алар бөек юлбашчыбыз, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинның икенче тапкыр котлавына лаеклы булдылар. Газетабызның 10 нчы март номерында урнаштырылган телеграммасында иптәш Сталин болай ди:

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә моннан элек кертелгән 100 миллион сумнан тыш өстәмә рәвештә «Советлар Татарстаны» исемле сугыш самолетлары эскадрильялары төзелешенә 100 миллион сум акча, Кызыл Армия өчен бүләкләр һәм җылы киемнәр җыйган, фронтовиклар семьяларына ярдәм күрсәткән хезмәт ияләренә минем туганлык сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз. И. СТАЛИН»

Юлбашчының котлавы республикабыз хезмәт ияләре өчен зур мактаныч, чиксез горурлык булып тора һәм әйтергә кирәк: аларның моңа бөтен нигезләре дә бар. «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасына акча җыюда колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар гаять зур активлык күрсәттеләр һәм кыска гына вакыт эчендә Дәүләт банкысына 100 миллион сум акча керттеләр. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин аларның бу патриотик эшенә гаять зур бәя бирде һәм үзенең аталарча җылы сүзләре белән туганлык сәламын һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен белдерде.

Иптәш Сталинның котлавы республикабыз колхозчылары арасында, эшчеләр, совет интеллигенциясе һәм барлык хезмәт ияләре арасында гаять зур политик һәм производство активлыгы тудырды.

— Мин бүген фронт өчен, Кызыл Армиягә ярдәм итү өчен нәрсә эшләдем һәм нәрсә эшләргә тиешмен? һәрбер совет кешесе үзенә көн саен әнә шундый сорауны куйды һәм фронтка ярдәмне барлык чаралар белән көчәйтә бару өчен бөтен көчен, белемен һәм барлык энергиясен бирде. Самолетлар эскадрильясы төзелешенә средство туплау кебек гаять зур патриотик башлангыч та нәкъ әнә шуның нигезендә туды. Менә, тагын да 100 миллион сум! Бу сумма да «Советлар Татарстаны» исемле сугыш самолетлары төзелешенә дип иң кыска вакыт эчендә җыелган средство. Бу бик күп нәрсәләр турында сөйли. Барыннан да элек ул, шундый дәһшәтле көннәрдә совет кешеләренең бары тик ватан интереслары белән генә яшәүләре турында, аларның хәзер ватанны саклаудан да өстен булган бурычлары юк икәнлеген яхшы аңлаулары турында сөйли.

— Бүген без, сезнең белән бергәләп, анабыз Идел ярларына басып, бабаларыбызның гадәте буенча Иделнең туфрагын үбеп, ант итәбез:

Кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә корал тотып сугышсак та, туган илебез өчен, аның азатлыгы, бәйсезлеге, намусы өчен җаныбызны аямабыз.

Татар халкының фронттагы үз улларына язган сәлам хатындагы бу сүзләренә республикабыз хезмәт ияләренең героик һәм патриотик эшләре тулысынча туры килә.

Республикабызның фронтка ярдәме кечкенә түгел. Ләкин бу әле һич тә тынычланырга мөмкин дигән сүз түгел. Алда әле авыр һәм кыен көрәш тора. Дошман әле көчле. Үзенең явыз уйларын тормышка ашыру өчен аның һәртөрле авантюраларга баруы мөмкин. Үз-үзеңне тынычландыру, гамьсезлек—ул совет кешеләре өчен бөтенләй хас түгел. Фронтка безнең ярдәмебез торган саен арта барырга тиеш. Фронт интереслары таләп итә икән,—ул берсүзсез үтәлергә тиеш!

Бөек юлбашчыбыз, Советлар Союзы Маршалы иптәш Сталинның котлавына халык хуҗалыгының барлык тармакларында да яңа уңышлар белән җавап бирик! Предприятиеләрдә, колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрик. Шуның нәтиҗәсендә, фронтка сугыш припаслары җитештерүне, Кызыл Армиягә, илгә икмәкне һәм авыл хуҗалыгының башка төр продуктларын бирүне тагын да арттырыйк.

— Барысы да фронт өчен, дошманны тар-мар итү өчен!

КОЯШ ШАҺИТ, ИДЕЛ ЙОРТ!

Туган илебезнең барлык җирен тәмам азат итеп бетергәнгә хәтле кылычларыбызны кынга салмабыз

(ФРОНТОВИК ТАТАРЛАРГА ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ СӘЛАМ ХАТЫННАН).

БЕЗНЕҢ ҖАВАП

ЧИСТАЙ, 12 март. (Телефон буенча). Тат. Талкыш авыл советына караган колхозларның членнары үзләренең саклык средстволарыннан танклар колоннасы төзү фондына 172 мең сум бирделәр. Самолетлар эскадрильясы төзүгә 73.822 сум тапшырдылар.

Шуның өстенә үз хуҗалыкларындагы запас ашлыктан Кызыл Армия фондына 186 пот ашлык, 55 центнер ит, 2.462 литр сөт, 1.218 килограмм бәрәңге бирделәр. Кызыл Армиянең 25 еллыгы бәйрәмен каршылау уңае белән генә дә 550 килограмм ит, 650 данә йомырка, 100 данә тире, 5.600 сум акча, күп кенә телогрейка, эчке киемнәр, тун һәм башка күп кенә әйберләр тапшырдылар.

Советлар Союзы Маршалы, даһи юлбашчыбыз иптәш Сталинның орденлы Татарстан хезмәт ияләренең сугышчан самолетлар эскадрильясы төзү өчен яңадан 100 миллион сум акча җыюлары уңае белән җибәргән телеграммасын укыгач, безнең авыл советына караган колхозларның членнары гомуми җыелышларында, немец-фашистлардан азат ителгән районнарга 5 баш эре терлек, 40 сарык, 2 сабан, 4 чәчү һәм бер ору машинасы бирү турында карар чыгардылар. Ерткыч бандитларга каршы геройларча сугышучы командирның анасы, «Чатки» колхозы члены Саҗидә апа Сафина танклар колоннасы төзүгә 3.000 сум, «Кызыл ялан» колхозы члены Ногман Галиев 1.000 сум, Кызыл Армия фондына бер сарык, 6 пот бодай, «Уракчы» колхозы члены Шакир иптәш Баһманов самолетлар эскадрильясы төзүгә 1.000 сум, Кызыл Армия фондына 6 пот бодай бирделәр.

Безнең авыл советына караган 8 колхозда язгы чәчүгә әзерлек эшләре тәгәлләнде инде. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәмамланды. Чәчүлек орлыклар барысы да чистартылып бетте.

— Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавына җавап итеп, колхозчылар язгы чәчүне яхшы итеп үткәрергә, игеннәрне яхшы итеп тәрбияләп үстереп, мул иген уңышы алу өчен көрәшергә, дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне срогыннан алда үтәргә сүз бирделәр.

Х. ХӨСНЕТДИНОВ,
Тат. Талкыш авыл советы председателе.

ТӨЯҮ һӘМ БУШАТУ ПЛАНЫ АРТТЫРЫП ҮТӘЛӘ

Буа тимер юл бүлеге работниклары арасында 1 нче Май алды социалистик ярышы киңәйгәннән-киңәя бара. Бүлек буенча дежур иптәш Ховеренко җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр сменасы соңгы көннәрдә зур уңышларга иреште. Бу смена хәзер төяү һәм бушату планын системалы рәвештә үтәп бара, техник эксплоатация кагыйдәләрен төгәл саклый. Иптәш Ховеренко сменасы дежур торган вакытта поездлар югары техник тизлек белән йөриләр.

Партоешма секретаре иптәш Мокеева булган заводта иптәш Сталинның котлау телеграммасы алыну уңае белән үткәрелгән митинг күренеше. Котлау телеграммасын цех начальнигы иптәш Ф. Азмитов укый.

И. Попков фотосы.

ЗУР БЕРДӘМЛЕК БЕЛӘН

Иптәш Сталинның Татарстан хезмәт ияләренә җибәргән туганлык сәламы һәм Кызыл Армиянең рәхмәте промкооперация артельләре членнары арасында гаять зур шатлык тудырды. Шул уңай белән Казандагы барлык артельләрдә митинглар, беседалар үткәрелде.

«Азат хатын» артелендә үткәрелгән митингта стахановчылардан иптәш Сөләйманова һәм башкалар чыгып сөйләделәр. Алар барлык эшчеләрне бөек юлбашчының котлавына лаеклы җавап бирергә, фронт һәм ил өчен тагын да зуррак энергия белән эшләргә чакырдылар.

Артель коллективы үз өстенә конкрет йөкләмәләр алды.

— Без март ае планын арттырып үтәрбез.

— Хезмәт җитештерүчәнлеген кимендә 15 процентка арттырырбыз.

— Прогулларга һәм эшкә соңга калып килүләргә юл куймабыз.

— Тик яхшы сыйфатлы гына продукция бирербез,—диделәр артель членнары.

ЭШ ТЕМПЛАРЫ ҮСӘ БАРА

Н-че заводның столяр-паяль цехында халыкара хатын-кызлар көне—8 нче март хөрмәтенә оештырылган стахановчы вахтага йомгак ясалды. Производствода кайбер тоткарлыклар булуга да карамастан, вахтага баскан эшчеләр барысы да алган йөкләмәләрен тулысынча үтәп чыктылар.

Паяльщица иптәш Вәлиева эшләп чыгаруны көннән-көн арттыра барды. Мәсәлән, ул 6 нчы мартта планны 122 процентка, икенче көнне 146 процентка, 8 нче мартта — 231 процентка үтәде, ә башка көннәрдә инде 231 дән алып 269 процентка кадәр үти башлады.

Паяльщица иптәш Вәлиуллина эштә югары күрсәткечләр бирүгә иреште. Стахановчы вахтаның соңгы 6 көне эчендә ул смена заданиеләрен 204 тән 288 процентка кадәр үтәде. Паяльщица иптәш Сәгъдиева, сменасына өч норма биреп, паяль мастерское буенча рекорд куйды.

Столяр иптәш Фадеев та темпларын арттырды. Вахтаның беренче көнендә ул заданиене 125 процентка үтәгән булса, соңгы көнендә 190 процентка үтәүгә иреште.

Стахановчы вахтага баскан 29 кеше арасында смена заданиесен 120 процент тан да ким үтәгән берәү дә юк. Барлык эшчеләр дә партия һәм профсоюз оешмаларының үзләренә күрсәткән ышанычларын акладылар.

Стахановчы вахтаның барышы цех стена газетасында һәм сугышчан листокта яктыртылды. Вахтага баскан эшчеләрне эш урынына кызыл флаглар куелды.

15 нче мартган цехтагы күпчелек эшчеләр 1 нче Май хөрмәтенә оештырылган стахановчы вахтага басачаклар.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында

(ДӘВАМЫ)

Халыкара коммунистик хатын-кызлар көне—8 нче мартны истә калдыру теләге белән промышленностьның, авыл хуҗалыгының, фәннең, техниканың һәм сәнгатьнең алдынгы хатын-кызларыннан түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләргә:

34. Рита Абрамовна **Борконы**—ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты транспорт бүлеге мөдире.

35. Анна Борисовна **Брильянщикованы**—врач, Чистайдагы фельдшерлык-акушерлык мәктәбе укытучысы.

36. Мария Львовна **Брусенцованы**—Н-че завод эшчесе.

37. Матрена Логиновна **Бушмарованы** — ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының җыештыручысы.

38. Камилә **Борһанованы**—Ленин исемендәге заводның токаре.

39. Фәүзия Габдулла кызы **Борһанованы**—Саба районы, Азин МТС ы политбүлеге начальнигының комсомол буенча ярдәмчесе.

40. Анастасия Ивановна **Бычкованы** — Казандагы 1 нче инфекция больницасының санитаркасы.

41. Җамал Гали кызы **Вазиевапы**—Казан педагогия институты укытучысы.

42. Зөләйха Мәрдән кызы **Вәлиәхметованы**—Казан психиатрия больницасының бүлек мөдире.

43. Ольга Ивановна **Волкованы**—Аксубай районы, «Большевик» совхозының бозау караучысы.

44. Анна Григорьевна **Воробьеваны** — Н-че заводның балалар яслесе мөдире.

45. Людмила Николаевна **Варфоломееваны**—Казан нефть базасының өлкән бухгалтеры.

46. Сара Мөхәмәтҗан кызы **Вяселеваны**—Казан медицина институтының өлкән ассистенты.

47. Зәйтүнә Гатият кызы **Габидуллинаны**—Чистайдагы «Красная звезда» агач заводы эшчесе.

48. Суфия Габит кызы **Габитованы**—Н-че завод эшчесе.

49. Әминә Ибраһим кызы **Галиеваны**—Казан шәһәр промкомбинатының скорняктегү фабрикасы эшчесе.

50. Гайшә Җәләлетдин кызы **Галимбековапы**—Казан тимер юлының вагон проводнигы.

51. Бикә Гатаулла кызы **Гайнуллинаны**—Казан мехкомбинаты эшчесе.

52. Зәйнәп **Гайнуллинаны**—эвакогоспиталь санитаркасы.

53. Марзия Латыйп кызы **Галиуллинаны**—Вахитов исемендәге жиркомбинат эшчесе.

54. Екатерина Сергеевна **Галицкаяны**—врачларның белемен күтәрү институты ассистенты.

55. Анастасия Федоровна **Галкинаны**—Ленин исемендәге завод эшчесе.

56. Шәмсебану **Галләмованы**—Бондюгтагы Н-че завод мастеры.

57. Валентина Александровна **Галочкинаны**—ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты машинисткасы.

58. Ирина Васильевна **Гаранинаны**—Мамадыш районы, «Мамадыш» совхозының бозау караучысы.

59. Анастасия Фоминична **Гарастины**—ВКП(б) ның Сталин райкомы секретаре.

60. Хәйриҗамал **Гарипованы** — ясалма күн заводы эшчесе.

61. Салиха Гарифулла кызы **Гарифуллинаны**—Мамадыш районы, «Агробаза» совхозының дуңгыз караучысы.

62. Камилә Ислам кызы **Гафарованы**—эвакогоспиталь врачы.

63. Фатима Гафар кызы **Гафарованы**—ВКП(б) ның Бауман райкомының кадрлар бүлеге мөдиренең урынбасары.

64. Зоя Егоровна **Герасимованы**—Заинский районы, Югары Пәнәче тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы.

65. Хәбирә Нурулла кызы **Гыйсмәтуллинаны**—ВЛКСМ ның Мамадыш райкомы секретаре.

66. Евдокия Андреевна **Гиданы**—Н-че завод эшчесе.

67. Анисия Павловна **Горбунованы**—Казан өлкә психиатрия больницасының өлкән медсестрасы.

68. Надежда Осиповна **Гордееваны**—Биектау районы, «Красный путь» колхозының умартачысы.

69. Любовь Евсеевна **Голосовскаяны**—эвакогоспиталь врачы.

70. Евгения Лукояновна **Гребневаны**—Чистай шәһәрендәге башлангыч мәктәп укытучысы.

71. Анна Ивановна **Григорьеваны**—Н-че завод эшчесе:

72. Нина Ивановна **Григорьеваны**—Казан шәһәрендәге 20 нче номерлы мәктәп укытучысы.

73. Нина Михайловна **Гурованы**—Казан тимер юлы политбүлеге инструкторы.

74 Наталия Ивановна **Гусеваны**—Н-че завод эшчесе.

75. Пелагея Алексеевна **Давыдованы**—Н-че завод мастеры.

76. Елена Павловна **Давтогорскаяны**—Чистайдагы суднолар ремонты заводы эшчесе.

77. Антонина Павловна **Дарьинаны**—Чистайдагы суднолар ремонты заводы токаре.

78. Прасковья Сергеевна **Демидованы**—Печищедагы 1 нче номерлы он заводы мастеры.

79. Мария **Дергунованы**—Чүпрәле районы, Чапаев исемендәге колхозның дуңгыз караучысы.

80. Пелагея Трофимовна **Деревяшкинаны**—Алексеевский районы, «Восход» колхозының дуңгыз караучысы.

81. Рабига Габдулла кызы **Дивееваны**—эвакогоспиталь врачы.

82. Гөлчирә Әхмәт кызы **Динмөхәмметованы**—Н-че завод эшчесе.

83. Антонина Яковлевна **Донованы** — Казан шәһәре, Дзержинский районы, Осоавиахимның район советы председателе.

84. Екатерина Михайловна **Дорогованы**—Казан тимер юлының юллар ремонтлау эшчесе.

85. Валентина Николаевна **Дубровинаны** —Серго исемендәге завод эшчесе.

86. Елена Ивановна **Евстафьеваны** — Ленин исемендәге завод эшчесе.

87. Евгения Васильевна **Евтееваны** — Н-че завод эшчесе.

88. Антонина Сергеевна **Егорованы** — Горький исемендәге завод эшчесе.

89. Марина Ивановна **Егорованы**—Казан шәһәрендәге 1 нче инфекция больницасының санитаркасы.

90. Антонина Михайловна **Елинаны** — Мамадыш районы, «Мамадыш» совхозы тракторчысы.

91. Ольга Ивановна **Елисееваны** — Казан шәһәре, ВКП(б) ның Киров райкомының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары.

92. Александра Михайловна **Есинаны**—Чистайдагы автогараж җиһазлары заводы эшчесе.

93. Екатерина Ефимовна **Ефимованы** — Казан шәһәр промкомбинатының скорняктегү фабрикасы эшчесе.

94. Мария Васильевна **Ещенконы**—Н-че завод эшчесе.

95. Мария Степановна **Жирнованы** —Буа районы, Кият промсовхоз комбинатының дуңгыз караучысы.

96. Евгения Петровна **Жиронкинаны**—Куйбышев исемендәге фабрика эшчесе.

97. Анна Павловна **Жукованы** — 2 нче номерлы ТЭЦ эшчесе.

98. Екатерина Ивановна **Жукованы**—Н-че завод эшчесе.

99. Клавдия Александровна **Журинаны**—1 нче номерлы ТЭЦ эшчесе.

100. Мәүлия **Заһидуллинаны**—Казан киез итек-фетр фабрикасы эшчесе.

101. Рабига Хангәрәй кызы **Зәйнуллинаны**—Казан тимер юлының Эгерҗе бүлегендәге поезд-вагон мастеры.

102. Халия Сөнгатулла кызы **Зәйнуллинаны**—Н-че заводның 1 нче цех бригадиры.

103. Шәмсекамал **Зәйнетдинованы**—Теләче МТС ының трактор бригадасы бригадиры.

104. Анна Михайловна **Зайцеваны**—Столбище МТС ының тракторчы хатын-кызлар бригадасының бригадир ярдәмчесе.

105. Полина Васильевна **Зайцеваны** — 5 нче номерлы тегү фабрикасы эшчесе.

106. София Николаевна **Зайцеваны**—Н-че завод мастеры.

107. Гөлсем Закир кызы **Закированы** — Балтач районы, Янгул тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы.

108. Банат Зариф кызы **Зарипованы** — Чепья районы, Смаил урта мәктәбе директоры.

109. Татьяна Петровна **Зарубинаны** — ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире.

110. Анна Ефимовна **Захарованы** —Казан тимер юлының вагон проводнигы.

(Дәвамы бар).

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: яулап алынган аэродромда булачак очучылардан бер группа дошманнан очышның маршрутын билгелиләр. Уртада—майор С. Д. Зайченко.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

12 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

12 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Гжатскидан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Дошман каты каршылык күрсәтте һәм аерым участокларда контратакаларга күчте. Безнең частьлар гитлерчыларның каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм аларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Бер участокта Н-че часть сугышчылары, штурм ясап, халык яши торган ныгытылган бер пунктны алдылар һәм 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташладылар. Танкка каршы ата торган 8 орудие, 7 миномет һәм 26 пулемет кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр сугыш припаслары һәм төрле сугыш милекләре төялгән бер зур обоз кулга төшерделәр.

* * *

Харьковтан көньяктарак безнең гаскәрләр дошманның көчле атакаларын кире кайтардылар. Бер участокта артиллеристлар һәм бронебойщиклар немецларның 9 танкысын яндырдылар һәм зарарладылар, пехота төялгән 17 автомашинаны юк иттеләр. Харьковтан көнбатыштарак дошманның бик күп танклары һәм пехотасы, бер-бер артлы дулкын булып килеп, безнең позицияләргә штурм ясадылар. Немецлар, бик күп кешеләрен һәм техникаларын югалтып, безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алдылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар актив сугыш хәрәкәтләре алып бардылар. Сугышларның ике көне эчендә немецларның 15 орудиесе, 2 танкысы һәм 600 гә якын солдат һәм офицерлары юк ителде.

* * *

Льговтан көнбатыштарак безнең хәрәкәтчән отрядларыбыз дошманның тылына барып чыктылар һәм, кинәт удар ясап, немецларның көчле итеп ныгытылган бер терәк пунктын алдылар. Бу пунктның 2 рота гитлерчылардан торган гарнизоны бөтенләй юк ителде. Бер артиллерия батареясы, 6 миномет, 24 пулемет, бер азык склады һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде.

* * *

Киев өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды март башында тимер юл станцияләренә берничә тапкыр уңышлы һөҗүмнәр ясаган. Партизаннар станция корылмаларын җимергәннәр һәм гитлерчыларның азык базаларын туздырганнар. Бик күп ашлык, бәрәңге һәм башка продуктлар кулга төшерелгән һәм халыкка өләшеп бирелгән. Шул ук отрядның бер группа партизаннары берничә урында тимер юлга миналар куйганнар. Миналарга бәрелеп бер паровоз һәм автомашиналар төялгән 8 платформа шартлаган.

* * *

Курск өлкәсенең Михайловское районында немец-фашист кабахәтләр коточкыч җинаятьләр эшләгәннәр. Немецлар Холстинка поселогын бөтенләй яндырганнар һәм җир белән тигезләгәннәр, ә бөтен халыкны — картларны, хатын-кызларны һәм балаларны — пулеметлардан атканнар. Гитлерчылар яраланган кешеләрне янып торган йортларга ташлаганнар. Поселокта фашист палачлар кулыннан барлыгы 250 кеше һәлак булган. Поселок бөтенләй юк ителгән, һәм анда бер йорт та калмаган.

БЕЗНЕҢ ВОЕНФЕЛЬДШЕР

Ул үзе Татарстанда туып үскән. Озын, нечкә буйлы, һәрвакыт диярлек шат йөзле бу яшь фельдшерны медицина-санитария батальонында:

— Безнең военфельдшер, дип кенә йөртәләр. Чынлап та бу «безнең» сүзе юкка гына әйтелми. Ул чын мәгънәсе белән безнең фельдшер. Ул үз эшен яхшы белә, аны ярата, бөтен көчен биреп эшли. Авыруларга карата ул нык бирелүчәнлек, кайгыртучанлык күрсәтә, иң куркыныч вакытларда да, тормыш өчен куркынычлы моментларда да яралanучылар янына китми. Безнең военфельдшер Григорий Мукеевның тәүлек буе авырулар яныннан чыкмый эшләгән вакытлары еш була. Аны еш кына приказ белән ял иттерәләр. Ул, Н-че медицина-санитария батальонында яралыларны эвакуацияләү эшен башкарып килә. Яралы сугышчыларга үз вакытында ярдәм күрсәтүдә, аларны җылы, уңайлы торак белән, ашау-эчү белән тәэмин итүдә ул үрнәк эш алып бара. Дошманның һавадан булган һөҗүмнәре вакытында да безнең якташ Мукеев зур геройлыклар күрсәтә. Әнә шундый үз эшенә бирелүчәнлек, эштә куркусызлык, батырлык үрнәкләре күрсәткәне өчен, иптәш Мукеев «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнә. Эштә сыналган якташ комсомолдан партия сафына алына һәм үзенең героик эшен дәвам иттереп килә.

Безнең данлыклы военфельдшер Григорий Мукеев Татарстанның Кызыл Йолдыз районы, Владимир авылының колхозчысы, ул безнең мактаулы военфельдшер. Ул чын күңелдән җиңүгә хезмәт күрсәтеп килә торган безнең героик военфельдшер.

А. ӘХМӘТ.

Хәрәкәттәге армия.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

КОЛХОЗ ТИМЕРЧЕЛӘРЕ ЭШЕН ДӨРЕС ОЕШТЫРЫРГА

ҺӘРБЕР МАШИНАНЫҢ, ҺӘРБЕР ИНВЕНТАРЬНЫҢ ТӨЗЕК БУЛУЫНА ИРЕШЕРГӘ

Фронт айлыгының 9 нчы көне

Язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы дәвам итә. Республикабызның күп кенә колхозлары айлыкны оештыруга житди игътибар бирделәр һәм шуның нәтиҗәсендә язгы чәчүгә әзерлекнең барлык тармаклары буенча да яхшы гына уңышларга ирештеләр. Арча районының «Сукачы» һәм «Комбайн» колхозларын, Мөслим районының «Дусай», Октябрь районының «Үрнәк» колхозларын күрсәтергә мөмкин. Бу колхозлар язгы чәчүгә уңышлы итеп әзерләнәләр. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәгәлләнгән, чәчү орлыклары әзер, атларның торышы яхшы һ. б. Мондый колхозларны, билгеле, һәрбер районда табарга мөмкин. Безнең бурыч фронт айлыгында барлык колхозларның да язгы чәчүгә тулысынча әзерлекләрен тәэмин итүдән гыйбарәт.

Атка җигүле машиналарга һәм инвентарьга ремонт ясауны уңышлы итеп тәгәлләү дә шулай ук фронт айлыгы уңае белән алга куелган әһәмиятле бурычларның берсе. Бу эштә дә барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга, барлык машиналарның һәм инвентарьның төзек булуына ирешергә тиешбез. Бу өлкәдә колхоз тимерчесенең роле гаять зур. Ә күп кенә колхозларда бу кадрлар җитешми, шулай ук тимерчеләре бөтенләй булмаган колхозлар да бар. Шуңа күрә тимерчеләрнең эшен оештыруга, аларга эшләү өчен барлык уңайлы шартларны булдыруга нык әһәмият бирелергә тиеш. Тимерчеләрне оештыруда Мәлки МТС ы политбүлек работникларының инициативасын яхшы дип табарга кирәк. Алар язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы башлануга ук колхоз тимерчеләренең махсус киңәшмәсен чакырдылар. Киңәшмәдә тимерчеләр машиналарга ремонт ясауны уңышлы итеп башкару буенча күп кенә кыйммәтле киңәшләр бирделәр. Тимерчеләрнең киңәшләрен тормышка ашыру машиналарга ремонт ясауны тизләтүдә зур ярдәм итте.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ КАДРЛАР

Столбище МТС ы янында тракторчылар әзерләү өчен оештырылган курс үзенең эшен тәмам итте. Курста 41 кеше укыды. Шуларның 39 ы хатын-кызлар. Сынауларны 6 кеше «отлично» билгесенә, 12 кеше «яхшы» билгесенә тапшырдылар.

АЛТЫН КУЛЛАРНЫҢ БЕРСЕ ТУРЫНДА

Берәр яхшы оста турында сүз чыкса һәм аның эшенә бәя бирергә туры килсә, гадәттә кыска гына итеп әйтәләр: «Аның куллары алтын», диләр.

Кайбыч районының Сталин исемендәге авыл хуҗалыгы артеле тимерчесе иптәш Рогозин да әнә шундый алтын кулларның берсе. Машиналарны ул бик яхшы итеп ремонтлый. Әгәр дә карап йөртсәң, ул ремонтлаган машинада сезон буена һичбер тоткарсыз, рәхәтләнеп эшләргә була.

Иптәш Рогозинның тагын бик яхшы бер ягы бар. Ул—мактаулы инициатор. Күптән түгел генә әле, язгы чәчүгә әзерлек буенча фронт айлыгы башлану белән, Мәлки МТС ы политбүлеге колхоз тимерчеләренең киңәшмәсен үткәрде. Бу киңәшмәдә иптәш Рогозин авыл хуҗалыгы машиналарын язгы чәчүгә әзерләүне оештыру буенча бик яхшы тәкъдим белән чыкты. Ул тимерчеләре булмаган колхозларга тимерчеләрнең социалистик ярдәмен оештырырга киңәш бирде. Киңәшмә аның бу тәкъдимен алкышлап каршы алды.

Быел иптәш Рогозин үз колхозындагы машиналарга ремонт ясауга керешкәндә, алачыкта бер кисәк тә күмер юк иде. Правление тарафыннан әйткәнне көтмәстән, бу эштә дә үзе инициатива күрсәтте. Күмерне әзерләүне үзе оештырды.

Сталин исемендәге колхозның авыл хуҗалыгы машиналары язгы чәчүгә күптән әзер инде. Соңгы вакытларда иптәш Рогозин социалистик ярдәм тәртибендә «Ключ Октября» һәм Молотов исемендәге колхозларның да барлык авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясады.

Яңа кадрлар әзерләүне иптәш Рогозин үзенең төп бурычларыннан берсе дип белә. Ул быел гына әле 4 тимерче әзерләде. Хәзер ул тимерчеләр үз колхозларында тимерче булып эшлиләр.

Иптәш Рогозиннан башка тимерчеләр дә үрнәк алырга тиешләр.

И. КОНДРАТЬЕВ.

КОЛХОЗ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНӘ НӘРСӘ ҖИТЕШМИ?

Шушма колхозында (Шөгер районы) язгы кыр эшләренә әзерлекне күптән тәгәлләргә бөтен мөмкинлекләр бар иде. Кызганычка каршы, биредә ул мөмкинлекләрдән файдаланмыйлар.

Колхозда авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьларга ремонт ясау гафу ителмәслек дәрәҗәдә акрын бара: 41 сабанның 27 сенә генә ремонт ясалган, 3 чәчкечнең һәм 16 культиваторның берсенә дә ремонт ясалмаган. Шуңа карамастан, правление тимерчене үз эшеннән аерып, теләсә нинди колхозчы башкара алырлык эшләргә йөртә. Мәсәлән, биш көн буена рәттән ул ындыр табагында кар көрәүдә эшли. Тимерче алачыгы өчен әзерләнгән күмерне икенче урынга тоталар. Ә шул ук вакытта тимерчелектә күмер булмау сәбәпле эш кына эш тукталып тора.

Бер чәчкечнең ходовой көпчәге юк. Аны икенче колхозлардан бик ансат табарга була. Ә колхоз председателе Сәлимҗанов бу турыда уйлап та карамый.

Язгы кыр эшләренә 90 ат катнашачак. Ләкин бары 30 атка гына җитәрлек сбруй бар. Бигрәк тә дилбегә, йөгән шикелле нәрсәләр җитешми. Боларны күптән колхозның үзендә әзерләүне оештырырга кирәк иде. Монда исә каяндыр әзерне көтәләр.

— Сүс һәм мунчала юк, ди колхоз председателе иптәш Сәлимҗанов.

Бу да дөрес түгел. Колхозда бернечә гектардан җыелган киндер келтәләре бар. Аларны талкып сүс ясау эшенә бернинди өстәмә средство кирәк түгел. Шул ук сүстән җеп эрләп чәчү өстенә кирәкле капчык, торыпша кебекләрне сугуны оештырырга мөмкин иде. Правление бу эшкә дә игътибар бирми.

АБДУЛЛИНА, ВӘЛИӘХМЕТОВА, НАСИРОВА.

ҺӘРБЕР КОЛХОЗГА ҮЗ АГРОТЕХНИГЫ

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы һәрбер колхозда үзенең агротехнигын булдыру бурычын куйды. Арча район җир бүлеге пленумның бу күрсәтмәсен үтәү йөзеннән соңгы көннәрдә бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнә башлады. Моннан бернечә көн элек агротехниклар әзерләү өчен кустларда оештырылган курслар аркылы 53 яңа агротехник әзерләнде.

Шулай ук шушы көннәрдә район җир бүлеге тарафыннан оештырылган бригадирлар әзерләү курслары да үзләренең эшләрен тәмам иттеләр.

Район җир бүлеге агрономы иптәш Ибәтуллин, Урта Пошалым участогында 20 кешелек курс оештырып, аларны яхшы итеп укытып чыгарды. 120 сәгатьлек программа тулысынча үтәлде. Укучылар кырчылык бригадирлары булып эшләрлек күнегүләр алдылар. Шундый ук курслар Олы Бирәзә участогында да үткәрелде. Анда 15 кеше укыды.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.



«Динамо» фабрикасында. Рәсемдә: (алгы планда) фабриканың алдынгы стахановчыларыннан берсе иптәш Х. Саханова һәм механик Н. Чугунова иптәшләр.

С. Парфенов фотосы.

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННАРГА ЯРДӘМ

ӨЧ ФЕРМА ОЕШТЫРЫЛДЫ

БАЛТАЧ, 11 март. (Телефон буенча). Районның колхозчылары азат ителгән районнардагы колхозларга туганнарча ярдәм күрсәтәләр. «Марс» колхозының товарлыклы сөтчелек фермасы оккупантлардан азат ителгән районнарга җибәрү өчен 10 баш сыердан товарлыклы сөтчелек фермасы оештырды. «Кызыл ил» колхозы члennары 2 баш сыер, 5 баш сарык, бер парлы сабан бүләк иттеләр, «Кызыл көч» колхозы тимер ходлы бер арба, бер пар зигзаг тырма, бер парлы сабан һәм башка төрле авыл хуҗалыгы инвентаре бүләк итте.

Район буенча барлыгы 43 баш сыер, 51 баш сарык, 13 баш дуңгыздан торган 3 ферма оештырылды, 14 сабан һәм башка төрле авыл хуҗалыгы инвентаре җыелды.

УНТ ЦЕХЫ ЭШЧЕЛӘРЕ 1.500 ПАР АЯК КИЕМЕ ҖИБӘРӘЛӘР

«Спартак» комбинатының цехларында һәм бүлекләрендә немец басып алучылар изүеннән азат ителгән районнарга җибәрү өчен китаплар, кием-салым һәм башка әйберләр җыю эше киң җәелдерелде. Эшчеләр һәм инженер-техник работниклар азат ителгән районнарга җибәрү өчен планнан тыш продукция җитештерү буенча йөкләмәләр алалар. Унт цехы коллективы март аенда планнан тыш 1.500 пар аяк киеме җитештерәчәк. Хәзер аяк киемнәренең бер өлеше әлгерде дә инде.

ЯШЬ ЭШЧЕЛӘРНЕ МИН НИЧЕК ТӘРБИЯЛИМ

Цех администрациясе һәм партоешма тапшыруы буенча миңа яңа эшкә—бер группа һөнәр училищесы укучыларын слесарьлыкка өйрәтү эшенә күчәргә туры килде. Бу шактый кыен һәм катлаулы, шул ук вакытта мактаулы эш иде. Мин бу бурычны, аның җаваплылыгын тулысынча аңлаган хәлдә, үтәргә керештем.

Яшьләр арасында эшләгәндә, мастер—өйрәтүче генә түгел, тәрбияче дә булырга тиеш. Яшь эшчегә производство чыныгуы бирү белән бергә аның дисциплинасы, эштә һәм көнкүрештә үзен тотуы белән дә кызыксынырга, аның гомуми аңының үсүе белән дә шөгыльләнергә кирәк. Шуның өчен мин беренче көннәрдән үк өйрәтү эшемне тәрбия эше белән бергә бәйләп алып бара башладым.

Мин группаны кабул итеп алганда, анда дисциплина түбән иде. Эшкә соң килү яки бөтенләй чыкмый калу, эш вакытында эчке тәртипнең элементар кагыйдәләрен бозу фактлары булды. Медведев, Сурков, Димитриев кебек укучылар еш кына прогул ясадылар. Мондый хәлдә эшне алып барырга мөмкин түгел иде һәм мин үземнең алдыма, беренче чиратта, группада хезмәт дисциплинасын ныгыту бурычын куйдым. Моның буенча конкрет фактларны күрсәтеп, укучылар арасында беседалар уздырдым. Бу беседалар вакытында кайбер укучыларга оялырга һәм кызарырга туры килде. Аларның тормыш шартлары белән танышу өчен регуляр рәвештә гомуми торакларына йөрдем. Көнкүрешләрен, ял вакытларын оештыруда ярдәм иттем.

Һәрбер укучыга дус, олы иптәш, киңәшче булып якын килү нәтиҗәсендә мин аларның үземә хөрмәт белән ышанып карауларына ирештем. Бу хәл группада дисциплинасызлык күренешләрен бетерүгә, өйрәнү эшләрен уңышлы оештыруга мөмкинлек бирде.

Мин производствода өйрәтү эшләрен ничек башладым соң? Иң элек һәрбер укучының нинди участокта, нинди эшкә өйрәнергә теләвен белдем. Аннан соң укучыларның белемнәренә, сәләтлелекләренә һәм тырышлыкларына карап, аларны разрядларга бүлдем. Шул разрядлар буенча эш биреп өйрәнү программасын башладым.

Безнең группада программа тәгәл үтәлеп бара. Укучыларны программа буенча слесарьлык эшенә өйрәтү белән бергә, мин аларга станоктан, инструменттан, материаллардан ничек файдаланырга кирәклеген, производстводагы һәрбер нәрсәне җентекләп өйрәнергә һәм һәрбер нәрсәне күз алмасы кебек саклап тотарга кирәклеген аңлатам. Бу укучыларга хәзердән үк стахановчы хезмәт методларына өйрәнергә ярдәм итә.

Өйрәнү - производство эшләре группада социалистик ярыш нигезендә алып барыла. Үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә группадагы барлык укучылар производство программасын үтәп баралар. Родченко, Владимир Смирнов, Бужал кебек укучылар зурлар нормасын арттырып үтиләр. 8 кеше 4 нче разрядка экзамен бирделәр. 6 кеше—Николай Стерню, Богданович һәм башкалар—срогыннан элек программаны тәгәлләп, хәзер җаваплы участокларда үзлекләреннән эшлиләр.

Группа, өйрәнү-производство эшләрен башкару белән берлектә, җаваплы заданиеләрне үтәүдә цехка бик нык ярдәм итә.

Группадагы укучыларны квалификацияле эшчеләр итеп җитештерү өчен күп нәрсә эшләргә кирәк әле. Мин үземнән таләп ителгәннәрнең барысын да эшләрмен. Ләкин биредә цех коллективының да, һөнәр училищесының да якыннан торып булышуы кирәк. Ул вакытта без яшь кадрлар әзерләүдә тагын да зуррак уңышларга ирешербез.

Н. ИДРИСОВ,

Н-че завод мастеры.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

12 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

12 нче мартта Көнбатыш фронт гаскәрләре кискен штурмнан соң Вязьма шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

11 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, кыр һәм зенит артиллериясенең ун батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм дошманның тимер юл эшелонын җимерделәр.

* * *

Безнен гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерә барып, Вязьма шәһәрен һәм тимер юл узелын алдылар. Шәһәр өчен булган сугышларда безнең гаскәрләр дошманның 8 самолетын, 83 танкысын, 69 орудиесен, 222 пулеметын, 565 автомашинасын һәм тракторын, 57 паровозын, 515 вагонын, бик күп снарядлар, патроннар һәм башка хәрби милекләрне кулга төшерделәр. Дошман үтерелгән хәлдә генә дә 9.000 нән артык солдатларын һәм офицерларын югалтты.

* * *

Сычевкадан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган байтак пунктны алдылар. Бер участокта Газашвили һәм Куприянов иптәшләр командалыгындагы подразделениеләр, дошманның оборонасын сындырып, фланглардан ударлар ясап, немецларны ашыгыч рәвештә чигенергә мәҗбүр иттеләр. Гитлерчылар бик күп техникаларын, шул исәптән төрле калибрдагы 12 орудиеләрен ташлап калдырдылар. Темкинодан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр, немецларның каты каршылык күрсәтүләрен җиңеп, халык яши торган берничә дистә пунктны, (болар арасында район үзәге Знаменка да бар) алдылар.

* * *

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары, дошманны куып барып, халык яши торган бер зур пунктны алдылар, шул чагында немецларның 18 танкысы, 3 танкеткасы һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Харьковтан көньяктарак безнең гаскәрләр дошманның бик күп танкларына һәм пехотасына каршы каты сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмәнең частьлары гитлерчыларның бер-бер артлы ясаган 8 атакасын кире кайтардылар һәм дошманның 23 танкысын, 800 гә якын солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, немецларның өстен көчләренә каршы кан коюлы сугышлардан соң халык яши торган бер пунктны калдырдылар һәм оборонаның яңа чигенә урнаштылар.

Һава сугышларында бер көн эчендә немецларның 26 самолеты атып төшерелде.

* * *

Изюм районында дошманның 40 танк ярдәмендәге бер пехота полкы безнең позицияләргә атака ясады. Н-че частьның сугышчылары гитлерчыларның атакаларын кире кайтардылар һәм дошманның 11 танкысын, 4 транспортын һәм 300 гә якын солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта командиры өлкән лейтенант Миронов булган подразделение саклап торган чикләргә немецларның 20 авыр танкысы һөҗүм итте. Совет сугышчылары немецларның 7 танкысын җимерделәр һәм яндырдылар, бер ротага якын гитлерчыларны кырып ташладылар.

* * *

Безнең штурмовиклар дошманның Орелдагы аэродромына һөҗүм иттеләр. Бомба ударлары белән, пушка һәм пулемет уты белән немецларның 15 самолеты юк ителде һәм 20 гә якын самолеты зарарландырылды.

* * *

Житомир өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның гарнизоннарына берничә һөҗүм ясаган. Партизаннар халык яши торган пунктларга кинәт барып кергәннәр һәм гитлерчыларны кырганнар. Совет патриотлары дошманның 8 танкысын, солдатлар төялгән 11 автомашинасын, 2 ягулык складын һәм бер сугыш припаслары складын юк иткәннәр. Бер зур тимер юл станциясенең юл хуҗалыгын җимергәннәр.

Халык өчен үч алучылар дошманның 2 орудиесен, 3 батальон миномөтын, 18 пулеметын, 22 мең патронын һәм башка хәрби милекләрен кулга төшергәннәр.

* * *

Италия матбугаты соңгы вакытларда совет-немец фронтында Италия гаскәрләренең батырлыклары турында күп яза. Кампанияне Италиянең Россиядән кайткан 8 нче армиясенең солдатларына һәм офицерларына каратылган махсус приказ белән Муссолини башлап җибәргән. Ләкин Муссолини да, Италия газеталары һәм радиостанцияләре дә Италия дивизияләренең нәрсә белән аерылып торганлыклары турында рәтле бернәрсә дә әйтә алмыйлар. Совет-немец фронтындагы сугышларны үзләре күргән һәм шунда катнашкан кешеләр исә әйтә алалар. Совет Информбюросы Италиянең «Күнеэнзе» дивизиясенең плен алынган тыл начальнигы капитан Рао Франческоның белдерүен игълан иткән иде инде. Бу кеше түбәндәгеләрне әйткән иде: «Италиянең армия корпусы Россиядә чын һәлакәткә очрады... Чигенү вакытында Альп полклары тәртипсез халык төркеменә ошыйлар иде. Солдатлар һәм офицерлар паникага төшеп качтылар. Без тизләтелгән марш белән рәттән 18 сәгать бардык, ләкин безне Кызыл Армия китереп кыскан кләшщәдән ычкына алмадык. Юлда автомашиналарны, коралларны һәм азыкларны ташлап калдырырга туры килде. Бу коточкыч һәлакәт иде».

Плен алынган итальян капитаны Италия армиясенең тар-мар ителүе күренешен шактый төгәл сөйләп бирде. Чынлыкта исә совет-немец фронтында булган Италия дивизияләре барысы да юк ителделәр яки туздырылдылар. Ун меңнәрчә итальян солдатлары һәм офицерлары үтерелде, ун меңнәрчә кешеләр плен алынды. Хәзер итальян дивизияләре командирлары генерал Паскалини, генерал Реганья һәм генерал Баттисти үзләренең штаблары белән берлектә совет пленлыгында торалар. Италиянең 2 нче тау-укчы дивизиясенең 10.000 кешесе, 3 нче тау-укчы дивизиясенең 10.700 кешесе, 4 нче тау-укчы дивизиясенең 13.200 кешесе үтерелде һәм плен алынды. Башка дивизияләр дә шулай ук туздырылдылар һәм үзләренең яшәүләрен туктаттылар. Шулай итеп, итальяннарның 8 нче армиясеннән бернәрсә дә калмады. Шулай булгач Муссолини үзенең приказында кемгә мөрәҗәгать итә һәм кемне мактый икән? 8 нче итальян армиясенәме? Ләкин бу армия юк бит инде. Анардан бары тик кызганыч калдыклар гына калды һәм алар да сугыш кырыннан качтылар. Рим гадәте буенча, үлгән кешеләр турында бер дә начар сүз әйтергә ярамый. Муссолини шушы гадәтне саклый күрәсең. Ләкин әгәр дә Мусолини 8 нче армиянең ничә солдаты Россиядән әйләнеп кайтканлыкны әйтә алса ахшырак булыр иде.

АМЕРИКАНЫҢ МОСКВАДАГЫ ИЛЧЕСЕ СТЭНДЛИ ӘФӘНДЕНЕҢ БЕЛДЕРҮЕ ҺӘМ БУ БЕЛДЕРҮГӘ АКШ НЫҢ КАРАШЫ

НЬЮ-ЙОРК, 9 март. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Москвадагы хәбәрчесенең язуына караганда, Америка Кушма Штатларының Москвадагы илчесе Стэндли, Америка хәбәрчеләренә, минем уйлавымча Американың Россиягә күрсәтә торган ярдәме турында рус халкына информация бирелми, диган. Стэндли: «Мин рус матбугатында русларның Америкадан материаль ярдәм алулары турындагы хәбәрләрне бик тырышып эзләдем, ләкин бу ярдәмне бер генә дә чын-чынлап тануны тапмадым», диган.

ВАШИНГТОН, 9 март. (ТАСС). Бүген Америка Кушма Штатларының дәүләт секретаре хезмәтләрен башкаручы Уэллес, матбугат конференциясендә, үзенең Стэндлига телеграмма җибәргәнлеген һәм бу телеграммада Стэндлиның матбугат вәкилләренә ясаган белдерүенең текстын дәүләт департаментына җибәрергә кушканлыгын әйткән. Ләкин әле Стэндлидан җавап алынмаган. Аннан соң Уэллес, Стэндлиның бу белдерүенең Америка хөкүмәте белән алдан киңәшмичә эшләнгәнлеге турындагы мәсьәләгә тулы ачыклык кертергә теләвен белдергән.

Вәкилләр палатасының чит ил эшләре комиссиясе председателе Блум, дәүләт департаменты белән киңәшкәннән соң, вәкилләр палатасында, Стэндлиның чыгышы «бик уңышсыз», диган. Блум түбәндәгеләрне әйткән: «Рус газеталарын карап чыкканнан соң, без аларны Америкадан Россиягә күрсәтелә торган хәрби ярдәм турындагы хәбәрләрне тулысынча басып чыгарганлыкларын белдек. Совет матбугаты коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы законны тормышка ашыру уполномоченные Стеттиниусның Советлар Союзына Американың ярдәм итүенә кагылган белдерүен 23 нче январьда тулысынча игълан иткән. Минем фикеремчә, безнең Россиягә ярдәмебез турындагы хәбәрләр Россиядә тулысынча игълан ителәләр».

Америка сенатының чит ил эшләре комиссиясе председателе Коннэли, үзенең сенаттагы речендә, Стэндлиның чыгышы «гадәттән тыш уңышсыз», диган. Коннэли Американың ярдәме турында рус халкына информация бирелеп торганлыкны әйткән.

Уилки үзенен белдерүендә болай диган: «Кискен һәм уйлап әйтелмәгән белдерүләрдән зыян гына килергә мөмкин. Мин Америкада хәзерге вакытта яки киләчәктә Россиягә хыянәт итәргә теләгән бер генә кешене дә белмим. Шулай ук мин безнең Россиягә материаллар белән һәм башка фронтларда сугышлар алып бару белән ярдәм күрсәтүебезне Россиядә кем булса да белми торгандыр дип уйламыйм».

НЬЮ-ЙОРК, 10 март. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәрчесе, Уэллесның матбугат конференциясендә ясаган белдерүенә комментарийлар биреп, Уэллесның әйтүенчә, ул Стэндлиның чыгышыннан канәгать түгел, диган. Нью-Йорк газеталары Уэллесның матбугат вәкилләренә ясаган белдерүен Стэндлиның чыгышыннан канәгатьләнмәүне белдерә торган заголовоклар белән игълан иттеләр. Шулай ук матбугат Уилкиның һәм Блумның белдерүләрен дә киң күләмдә игълан итә. Вашингтон хәбәрчеләренең әйтүенчә, дәүләт департаменты Уэллес чыгышының стенограммасын игълан итәргә рөхсәт итүе белән гадәттән тыш адым атлаган. Бу чыгышында Уэллес Стэндлины рәсми рәвештә гаепләвен кискенлек белән белдергән.

НЬЮ-ЙОРК, 10 март. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Москвадагы хәбәрчесе Кэссиди үзенең 5 нче март мәкаләсендә Советлар Союзына булган күзәтүләре турында язып, Американың Советлар Союзына күпме ярдәм күрсәткәнлеге СССР халкына билгеле икәнлекне әйтеп үтә. «Чөнки,—ди Кэссиди,—Рузвельтның һәм Черчилльнең бу мәсьәлә буенча булган барлык белдерүләре һәм аларга кагылган саннар совет матбугатында игълан ителәләр, ә руслар газеталарны бик тырышып укыйлар. Минем белән сөйләшергә туры килгән руслар үзләренең Американың ярдәменә бик югары бәя бирүләрен ачык итеп әйттеләр.

«НЬЮ-ЙОРК геральд трибюн» газетасының күптән түгел Москвадан кайткан хәбәрчесе Хиндус, радио буенча булган чыгышында, үзенең Стэндлиның белдерүенә риза түгеллеген игълан итте. Хиндус болай диде: «Советлар Союзына күрсәтелә торган ярдәм турында Рузвельтның белдерүләре совет матбугатында киң күләмдә игълан ителәләр. Ләкин совет матбугаты фронтка нәрсәләр җибәрелгәнлеге турындагы хәбәрләрне бирми, чөнки бу сугыш сере».

ЛОНДОН, 10 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгы үзенең Вашингтондагы хәбәрчесенең хәбәрен тапшыра. Бу хәбәрдә Уэллесның белдерүе Вашингтонда Стэндлиның позициясен гаепләү дип каралганлыгы әйтелә. Хәбәрченең әйтүенчә, Вашингтондагы дипломатия даирәләре, Уэллесның Америка хөкүмәтенең позициясен бик тиз аңлатып бирүе Американың хәзер генә түгел, бәлки сугыштан соң да СССР белән тулысынча бергә эш алып барырга теләвен тагын бер кат раслый.

Мәхәббәт һәм нәфрәт турында шигырьләр

Орденлы шагыйрь Шәйхи Маннурның фронттан язган ялкынлы шигырьләрен без зур канәгатьләнү белән укыйбыз, күзәтеп барабыз. Туплар гөрселдәгән, сугыш машиналары җирне һәм күкне тетрәткән урыннарда туган ул шигырьләрдә совет патриотларының горурлыгы чагылдырылган, изге совет җирләреннән немец шакшыларны куып чыгаруыбызга ышаныч белән сугарылган.

Ватан сугышы көннәрендә Маннур иптәшнең «Җиңүчеләргә сәлам» исемле бер җыентыгы чыгарылды. Бу җыентыкка сугышның беренче көннәрендә һәм, аннан соңгырак фронттан язылган 19 шигырь тупланган.

Маннур бүгенге хәлләрне, һәр яңалыкны, сугыш чорында туган вакыйга, фактларны күрә һәм шагыйрь йөрәге белән сизә. Ул үзенең шигырьләрен фашистлар кулына эләкмәс өчен гранатасы белән үзен дә, дошманнарны да шартлаткан батыр старшина Курмаевка, сугышчы-шофер Ибраһим Сабитовларга («Халык улы», «Шофер һәм малай» һ. б.) багышлый. Ленинград халкының, Москваны саклаучы каһарманнарның батырлыкларын, совет халыкларының бердәмлеген, ышанычын, дошманга ачы нәфрәтен җырлый.

«Йөрәкләрдә безнең ачу бүген,
Иң аяусыз үчләр янгыны»,—ди шагыйрь.

Совет хатын-кызларын немец вәхшиләре мәсхәрәлиләр, үтерәләр, сабый бала яткан бишек астына мина салып шартлаталар. «Моңа нинди исем табарга?» дип сорый шагыйрь һәм:

«Юк, планета!
Мондый вәхшилеккә
Акыл җитми исем табарга.
Исеме дә юк моның,
Тиңе дә юк!
Җан тетрәнә моны язарга»—дип нәфрәтле юлларын яза.

Маннурның сугыш башындарак язган шигырьләрендә риторика, конкретсызлык кебек кимчелекләр очраган булса, фронттан язган шигырьләрендә инде без моны күрмибез. Фронт шигырьләре конкрет, үткен, хисле булулары белән аерылалар. Маннур форма ягыннан да оригиналь алымнар куллана, яңалык кертү юлы белән бара, героик-эпик жанрда уңышлы үрнәкләр биреп килә. Аеруча «Шофер һәм малай» балладасын шагыйрьнең иҗат уңышы итеп күрсәтергә кирәк.

Маннур—нигездә лирик шагыйрь. Һәм аның фронттан язган лирик әсәрләре аеруча елы, йөрәккә керерлек итеп, чын күңелдән иҗат ителгәннәр («Язгы сәламнәр» һ. б.). «Сез көтегез безне» кебек лирик шигырьләре музыкага салырлык лирик җыр булып яңгырыйлар.

Маннурның хәзерге шигырьләрендәге төп тема, төп мотив—мәхәббәт һәм нәфрәт. Патриот шагыйрь өчен ул бик табигый, һәм ул шулай булырга да тиеш. Безнең ватаныбызга, туган халкына, Кызыл Армиягә, совет халкының батыр улларына һәм кызларына мәхәббәт һәм дан җырлый шагыйрь. Безнең изге җиребезне таптап, чәчәк аткан авыл, шәһәрләребезне яндыручы һәм бөек культурабызны, иркебезне җимерергә теләүче немец вәхшиләренә мең ләгънәт, нәфрәт һәм үч яңгырый.

«Кайнар сәлам сезгә, гвардеецлар,
Алга барган асыл егетләр!
Күтәрелде җылы кояш булып,
Озак көткән якты өметләр».

Москва янында немецларны тар-мар итүче гвардеецларга багышланган бу юллар да шундый ук көчле һәм урынлы. Без бүген Сталинград, Воронеж, Ростов, Харьков шәһәрләрен азат итүче батырларыбызга шундый ук ялкынлы, шатлыклы сәламнарыбызны җибәрәбез.

Фронтовик шагыйрь Ш. Маннурның иҗаты ватан сугышы чорында тагын да үсә, киңәя баруына шатланып, киләчәктә ватан сугышының бөек темасын, совет кешеләренең искиткеч героикасын чагылдырган киң колачлы поэтик әсәрләр тудырыр дип көтәбез.

Х. ХӘЙРИ.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 101 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 442